МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

09.03.2023 г. Казань № 153-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 87-осн номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 мартындагы 146-осн номерлы, 2022 елның 7 ноябрендәге 551-осн номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.2 пунктның «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 25 июлендәге 386-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе,» сүзләре белән алыштырырга;

5.4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе,» сүзләре белән алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 9 ноябрендәге 1068-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эмблемасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 11 февралендәге 43-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

4.12 пунктның 4.12.4 пунктчасында:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

5. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров